# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Иске Эсләк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Иске Эсләк торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**03.12. 2021** **№1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының районының «Иске Эсләк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Иске Эсләк торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 2021 елның 03 декабрендә 08:30 сәг уздырылган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2022 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Иске Эсләк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Иске Эсләк торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

1) Иске Эсләк авылы шартнамәсе буенча урам яктырткычлары өчен яктылык диодлы лампалар сатып алу, урнаштыру, эшләр өчен түләү;

2) Иске Эсләк авылында халыкны су белән тәэмин итү (ремонт, хезмәт күрсәтү, шартнамә буенча түләү, су белән тәэмин итү өчен тирәнлек насослары һәм төзелеш материаллары сатып алу);

3) Иске Эсләк авылында юлларны кардан чистарту;

4) Иске Эсләк авылында корыган агачларны кисү;

5) Иске Эсләк авылында су җыю башнялары һәм скважиналары астында җирләрне ызанлау;

6) Иске Эсләк авылы мәдәният йортының техник документациясен эшләү;

7) хуҗасыз йортларны карап тоту, тышкы фасадларны яңарту, койма белән әйләндереп алу;

8) янгын сүндерү автомобиленә ГСМ сатып алу.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 221 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 116 кеше, бу 52,4 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 116 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Иске Эсләк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Иске Эсләк торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенынын нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2. 2022 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Иске Эсләк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Иске Эсләк торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм ирektән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертергә.

3. Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

1) Иске Эсләк авылы шартнамәсе буенча урам яктырткычлары өчен яктылык диодлы лампалар сатып алу, урнаштыру, эшләр өчен түләү;

2) Иске Эсләк авылында халыкны су белән тәэмин итү (ремонт, хезмәт күрсәтү, шартнамә буенча түләү, су белән тәэмин итү өчен тирәнлек насослары һәм төзелеш материаллары сатып алу);

3) Иске Эсләк авылында юлларны кардан чистарту;

4) Иске Эсләк авылында корыган агачларны кисү;

5) Иске Эсләк авылында су җыю башнялары һәм скважиналары астында җирләрне ызанлау;

6) Иске Эсләк авылы мәдәният йортының техник документациясен эшләү;

7) хуҗасыз йортларны карап тоту, тышкы фасадларны яңарту, койма белән әйләндереп алу;

8) янгын сүндерү автомобиленә ГСМ сатып алу.

4. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Авыл җирлеге башлыгы

Совет Старосляковского сельского поселения
Иске Эсләк авыл җирлеге Советы
АГРЫЗСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИНН 1601002580

Д.М.Әхмәтов